ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17.11.2020 с.Старое Дрожжаное № 605

Чүпрәле муниципаль районы бюджетыннан Чүпрәле муниципаль районы үзәгеннән 11 километр ераклыкта урнашкан Чүпрәле муниципаль районының ерак һәм аз халык яши торган авыл пунктларына беренче чиратта кирәкле товарларны китерү белән бәйле рәвештә, кулланучылар кооперациясе оешмалары чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибенә үзгәреш кертү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 16 октябрендәге 471 номерлы карары белән расланган Чүпрәле муниципаль районының район үзәгеннән 11 чакрым ераклыкта урнашкан Чүпрәле муниципаль районының ерак һәм аз халыклы авыл пунктларына беренче чиратта кирәкле товарларны китерүгә бәйле кулланучылар кооперациясе оешмалары чыгымнарының бер өлешен каплауга Чүпрәле муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә, түбәндәге эчтәлекле 2.1 пунктны өстәп, үзгәреш кертергә:

«- Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычларның булмавын раслый торган документлар;

- Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетына субсидияләр, бюджет инвестицияләре, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән бюджет инвестицияләрен кире кайтару буенча кичектерелгән бурычның булмавын һәм Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджеты алдында срогы чыккан бүтән бурычның булмавын раслаучы документлар.».

2. Әлеге карарны Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Башкарма комитет җитәкче Д.А.Сатдинов